ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**05.05.2023ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1351**

Зеленодольск шәһәрендә транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган бәйрәм чараларын үткәрүгә әзерлек кысаларында, шулай ук җәмәгать һәм террорчылыкка каршы иминлекне тәэмин итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елның 08 маенда Зеленодольск шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының түбәндәге участокларында 18.00 сәгатьтән 21.00 сәгатькә кадәр бәйрәм массакүләм чараларын үткәрү чорында җәяүлеләр зонасын оештырып транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча туктатуны гамәлгә ашырырга:
- Карл Маркс урамы белән кисешкәннән алып Ленин урамы белән кисешкәнгә кадәр Яшьлек урамын.
2. 2023 елның 09 маенда Зеленодольск шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының түбәндәге участокларында 08.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр бәйрәм массакүләм чараларын үткәрү чорында җәяүлеләр зонасын оештырып транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча туктатуны гамәлгә ашырырга:
- Заикин урамы чатыннан алып Беренче Май урамы чатына кадәр Ленин урамын;
- Карл Маркс урамы чатыннан алып Ленин урамы чатына кадәр Татарстан урамын.
- Карл Маркс урамы белән кисешкәннән алып Ленин урамы белән кисешкәнгә кадәр Яшьлек урамын.
3. Татарстан Республикасы Зеленодольск районы буенча ЭЭМ бүлегенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:
- әлеге карарның 1 пункты нигезендә Зеленодольск шәһәрендә чаралар үткәрүне тәэмин итү өчен барлык төр транспорт чаралары хәрәкәтен туктатуны оештырырга;
- бәйрәм барышында катнашучыларның һәм тамашачыларның иминлеген тәэмин итү, аларны үткәрү чорында транспорт хәрәкәтен җайга салу буенча кирәкле чаралар күрергә;
- чаралар уздыру урыннарына якын урамнар участокларындагы оператив хәлне исәпкә алып, транспорт хәрәкәтен чикләү яки ябу буенча карарлар кабул итәргә.
4. Пассажирлар транспорты хәрәкәтен «Зеленодольск муниципаль районының төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ Зеленодольск шәһәренең Карл Маркс урамында оештырырга.

5. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В.Старостин